РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ГЛАВА НОВОИГАЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯНА ИГЛАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | с.Новое Иглайкино | КАРАР

«21» октябрь 2020 ел | № 2

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге Якты Күл авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, "Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елның 6 ноябрендә 10сәгать 00 минутта Якты Күл авылы, Центральная урамы, 30Б адресы буенча урнашкан Якты Күл КФҮ бинасында Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлегенең Якты Күл авылында Үзәк, Клуб, Юл, Болын урамында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2020 елның 6 ноябрендә 12 сәгать 00 минутта Елга урамы буенча 24нче йорт янында Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлегенең Якты Күл авылында Елга урамында, Елга тыкрыгы урамында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Гражданнар җыенын уздыру өчен Якты Күл авылында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

4. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Яңа Иглай авыл җирлеге Якты Күл авылы территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидларыннан тыш, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, хәрби хәрәкәтләр ветераннарыннан, ялгыз яшәүче 75тән өлкәнрәк гражданнардан кала 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Якты Күл торак пункты чикләрендә авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау;

Урамнарны яктыртуны оештыру өчен, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр, товарлар сатып алу»

«РИЗА» «КАРШЫ»

8. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә), Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Яңа Иглай авыл җирлеге Якты Күл торак пункты мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы Р.И. Фәйзуллин